**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «22» июленнән № 298

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2019 елның 15 апрелендәге 103 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 декабрендәге 390-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль торак контролен гамәлгә ашыруның административ регламентын раслау турында» 2019 елның 15 апрелендәге 103 номерлы карарының 12 абзацының 3.3.1. пунктындагы «1) дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомление нигезендә, юридик зат, индивидуаль эшкуар тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау һәм күпфатирлы йортларда гомуми милекне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү һәм (яки) эшләр башкару;» сүзләрен «1) дәүләт торак күзәтчелеге органына тапшырылган уведомление нигезендә, торак милекчеләре

ширкәте, торак, торак-төзелеш кооперативы яки башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыра башлау;» сүзләренә алыштырырга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://parvo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www. novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов